**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы**
**Иске Дөреш авыл җирлеге составына керүче Октябрь-Бүләк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

25 октябрь, 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Иске Дөреш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2024 елның 25 нче октябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Октябрь-Бүләк авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- **урам яктырту эшләрен башкару (урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу).**

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 61 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 34 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
**«Әйе»** позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 34 кеше тавыш бирде;
**«Юк»** позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Октябрь-Бүләк авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2025 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Октябрь-Бүләк авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- **урам яктырту эшләрен башкару (урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу)**

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Иске Дөреш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Октябрь-Бүләк авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

5. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Октябрь-Бүләк авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков

Совет Стародюшского сельского поселения
ОГРН 1021603013780
р 05-11794/09
ИНН 1639009730